**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы утырышы**

**КАРАРЫ**

“20” февраль 2026 № 15

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2026 елның 28 гыйнварындагы 02-08-03-2026/Прдп19-26 номерлы күрсәтмәсе нигезендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- ““Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына “Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында” 2017 елның 22 августындагы 62 номерлы карары;
- “Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 62 номерлы карары белән расланган “Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына “Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” 2022 елның 29 августындагы 55 номерлы карары;
- ““Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына “Олы Әтнә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында”гы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2023 елның 18 августындагы 72 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Хисамиев Р.Ш.